# Инспекторлар баланы коткарган

ИМИН ЮЛ

**Дәүләт автоинспекциясе хезмәткәрләре бер баланы хастаханәгә илтергә булышкан.**



Биш яшьлек бала ишегалдында уйнаганда абынып, башы белән профнастил читенә киселгән. Әнисе аны хастаханәгә илткәндә, баланың җәрәхәтеннән көчле кан ага башлагач, ул юлда торган инспекторларга мөрәҗәгать иткән. ЮХИДИ идарәсенең полиция лейтенанты Альберт Сабирҗанов, полиция сержанты Владимир Андреев малайны тиз арада Республика балалар клиник хастаханәсенә илткәннәр.

Юл инспекторларының оператив эшләүләре нәтиҗәсендә, балага вакытында медицина ярдәме күрсәтә алганнар. Хәзер малайның хәле канәгатьләнерлек. Ул юл имилеге инспекторларына рәхмәт йөзеннән үзе ясаган рәсем бүләк иткән. Ә ЮХИДИ хезмәткәрләре малайга йомшак уенчык һәм юллардагы куркынычсызлыкны сакларга өйрәткән белешмәләр, яктылык кайтаручы элементлар тапшырган, гаиләгә имин юллар теләгән.

# ТНВ бәйрәм телемарафоны уздыра

**Быел ТАССР төзелүнең 100 еллыгы республика тарихында иң мөһим вакыйгаларның берсе.**

«Яңа Гасыр» телеканалы 27 майда иртәнге 6дан төнге сәгать 12гә кадәр барачак махсус телемарафон әзерләде.

Эфир татар һәм рус телләрендә чыга торган «Манзара» һәм «Здравствуйте» иртәнге тапшыруларыннан башлана. Аларны «Татарлар» тапшыруы алыштырачак.

**10:00** – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессиясенең тантаналы өлешеннән трансляция.

**11:30** – ТАССР төзелүнең 100 еллыгына багышланган «Без кабызган утлар…» дип аталган концерт.

**13:30** – «История татарстанского парламентаризма» тапшыруы.

**14:00** – «Вековая история» документаль фильмы.

**14:45** – «Минтимер Шаймиев. Без права на ошибку» – «Яңа Гасыр» телекомпаниясе генераль директоры Илшат Әминевның Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев белән әңгәмәсе.

**16:30** – ТАССР төзелүнең 100 еллыгына багышланган «Вехи истории» тарихи фильмнар циклы.

**21:00** – прайм таймда, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка багышланган «Вехи истории» махсус чыгарылыш.

**22:00** – «Без кабызган утлар…» концерты.

Реклама

КУЛЛАНУЧЫ ХӘБӘРЛӘРЕ

# Массаж кәнәфие

**«Мин үземне алдадылар дип уйлыйм, чөнки миңа массаж кәнәфиен кредитка коточкыч бәягә – 120 мең сумга саттылар! Консультант-таратучы тәкъдим иткән килешүгә һәм ниндидер кәгазьләргә кул куеп, аны ничек сатып алуымны аңламый да калдым. Хәзер аңлавымча, мине, лаеклы ялдагы кешене, төп башына утырткannар. Нәтиҗәдә, мин хәзер банкка гаять зур күләмдә акча түләргә тиеш. Мин үз акчаларымны ничек кире кайтара алам, чөнки бер пенсиягә генә яшим бит?»**

**Ш.Гыйльманов**

Әгәр Сез кредит килешүенә һәм массаж кәнәфиен сатып алу-сату турындагы килешүгә кул куйгансыз икән, килешүдә хуҗалык итүче субъектның атамасы, юридик адресы (урнашкан урыны), сатучының банк реквизитлары һәм телефоннары күрсәтелергә тиеш.

**! Беренче чиратта, Сезгә күрсәтелгән реквизитлар буенча дәгъва юлларга, килешүне өзү һәм акчаны кире кайтару турында үз таләпләрегезне белдерергә кирәк.**

«Кулланучыларның хокукларын яклау турында»гы Россия Федерациясе Законы нигезендә, таләпләрне канәгатьләндерү вакыты 10 көн тәшкил итә. Законлы таләпләр ирекле нигездә канәгатьләндерелмәгән очракта, Сезнең кулланучы буларак үз хокукларыгызны яклауны сорап судка мөрәҗәгать итәргә хакыгыз бар.

**Дәгъва һәм дәгъва гаризасы проектын төзүдә бушлай ярдәм сорап, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә яки аның территориаль органнарына мөрәҗәгать итә аласыз. Алар, үз вәкаләтләре кысаларында, кулланучыларның хокукларын яклау мәсьәләләре буенча эшчәнлек алып бара, хатлар, гаризалар, шикаятьләр, ведомство компетенциясендәге мәсьәләләр буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карый. Кулланучыларның хокуклары бозылган очракта, аларның административ йогынты ясау буенча чаралар күрергә хакы юк.**

# Чек юкмы? Кайгырмагыз!



**«Күптән түгел иремнең туган көне булды. Бүгенге эпидемиологик вәзгыять шартларында бүләк сатып алу – зур проблема, шунлыктан интернет-кибеттән файдаланырга уйладым. Иремә күлмәк сайладым: фотода ул матур һәм сыйфатлы күренде. Күлмәкне сатып алганда банк картасы белән түләдем, ул шактый кыйммәткә төште. Әмма, кызганыч ки, күлмәк сыйфатсыз булып чыкты. Моңа кәефем кырылды, чөнки товарны кире кайтару өчен чегым да юк иде. Миңа сатып алу фактын ничек расларга?**

**А.Соколова»**

Әгәр сезнең касса яки товар чегы, хезмәткә акчасыз түләнүен күрсәткән чек яки товар сатып алу фактын һәм шартларын раслый торган башка документыгыз юк икән, бу – сатучыга карата таләпләрегездән баш тарту өчен сәбәп түгел.

«Кулланучыларның хокукларын яклау турында»гы РФ Законының 18 маддәсе 5 пункты һәм РФ Гражданнар кодексының 493 маддәсеннән чыгып, кулланучы килешү төзү фактын һәм аның шартларын шаһит күрсәтмәләренә сылтама белән расларга хокуклы.

Товарны дистанцион юл белән саткан (эш, хезмәтләргә заказ биргән) вакытта, кагыйдә буларак, почта, интернет һәм телефон кулланыла. Шул ук вакытта, кулланучы товарга (эш, хезмәт) электрон юл белән яки банк хисабы аша түли.

**РФ Югары Суды Пленумының 2012 елның 28 июнендә дөнья күргән «Судлар тарафыннан кулланучыларның хокукларын яклау хакындагы бәхәсләр буенча гражданнар эшләрен карау турында»гы карарының 43 пункты нигезендә, сатып алу фактын банк счетыннан белешмә, шулай ук башка төрле документлар (мисал өчен, акчаны электрон юл белән күчергән клиентның боерыгын үтәү турында электрон оператор расламасы) белән дәлилләргә мөмкин.**